Мәктәп укучылары вертолет төзи

Вадим Лигай, завод җитәкчесе булгач, кадрлар кытлыгына юлыга. Олы яшьтәге тәҗрибәле белгечләрне алмаштырырлык яшьләр җитми. Булганнарының да белем дәрәҗәсе хәтта мәктәп программасын тартмый. Кайчандыр үзе дә заводта инженер-конструктор, технолог булып эшләгән Вадим Лигай югары дәрәҗәдәге белгечләрне мәктәптән үк әзерләргә кирәклеген шул вакытта аңлый.

5 БИТ

Аз да җитә, күп тә бетәме?

Шушы көннәрдә Татарстан Дәүләт Советында Рәшит Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале Попечительләр советының беренче утырышы үтте. Аның рәисе итеп Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев сайланды. Аның советына Дәүләт Советы депутатлары, фән һәм мәдәният эшлеклеләре белән бергә матбугат чаралары җитәкчеләре, шул исәптән «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Гөлнара Сабирова да керде.

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 14.03.2017 | №26 (5788)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«БЕЗ – МАТУРЛЫКНЫ ЯРАТУЧЫ ХАЛЫК»

VI Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенының пленар утырышына халык гадәттәгечә ике сәгать алдан җыйнала башлады. Авыл кешесеме инде ул сәгать суканны көтеп ята торган? Бигрәк тә көннәр язга авышкач.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

business-gazeta.ru

Һәр елдагыча быел да утырышка килүчеләр иң элек күргәзмә белән танышып чыкты. Безнең татар егетләре һәм кызлары кайларда яшәп, нәрсәләр генә җитештермиләр. Җитештерүчәнлек белән бергә фикерләү дә үзгәрә. Бүгенге көндә Россиянең татар авылларында яшәүче эшмәкәрләр үз эшләрен оештырып, халыкны эшле һәм ашлы итеп кенә калмыйча, без сагынып искә ала торган меценатлыкны кабат торгызып киләләр. Пенза өлкәсеннән Ренат Әбүзәров туган авылында үз акчасына мәктәп һәм балалар бакчасы төзеткән. Петербург һәм Уфадагы шундый ук матур эшләр турында ишетеп беләбез. Гомумән алганда да, пленар утырышта чыгыш ясаучыларның берсе генә дә үз бизнесы турында, авырлыклар турында сөйләмәде. Сөйләшүләрнең төп темасы ничек без бер-беребезгә файдалы була алабыз, ничек итеп авылларны, матур гореф-гадәтләребезне, телебезне, моңыбызны сакларга?

Халыкны иң җәлеп иткән чыгышларның берсе Башкортстаннан килгән Харис Идиятуллинныкы булгандыр.

– Без – матурлыкны яратучы матур халык һәм көннән-көн камилләшә барабыз. Кичә Балтач районына бардык. Безнең юлларыбызны чибәр кызлар белән буып, күңелләребезне тальян гармун белән биләделәр. Андагы тәртип, матурлык, без килә дип кенә аны бер төндә юып, чистартып булмый. Бу безнең каныбызда, җелегебездә, гадәтләребездә, – диде ул.

Харис Идиятуллин Рөстәм Миңнехановны туган көне белән котлап, сәламәтлек, сабырлык, Татарстанны һәм татарларны саклавын теләп, Татарстан халкына нәселле чабышкы айгыр бүләк итте.

– Элек без, авылда яшьләр калсын өчен, таш түшәлгән юллар кирәк, дидек. Аннан соң газ, су, интернет... Боларның барысы да бар, шулай да халык авылдан китә дә китә. Авылларны җимерү өчен ниндидер күзгә күренмәс схема эшли кебек. Чынлыкта исә сәбәпләр күпкә тирәндәрәк икән, – диде үзенең чыгышында Башкортстанның Дүртөйле районы Әсән авылы кошчылык фабрикасының Директорлар советы җитәкчесе Зифкат Сәйтгалиев.

Аның фикеренчә, эшмәкәрләр күп каршылыкларга очрыйлар, төрле трибуналардан күп тапкырлар әйтелсә дә, уңай якка үзгәрешләр бик күренми.

– Мин сезнең чыгышларның һәркайсын зур игътибар белән тыңлап утырдым. Безгә Татарстанда сездән өйрәнергә кирәк. Сез безгә үрнәк: мәктәпләргә, мәчетләргә, мәдәният йортларына ярдәм итәсез. Очрашуның мондый форматы да бик кирәк. Интернеттан укыдым, кемнәрдер безне тәнкыйтьли, әгәр дә без аралашмыйбыз, тәҗрибә уртаклашмыйбыз икән, элемтәләр югалачак, бердәмлек бетәчәк. Бердәм булсак, барлык авырлыкларны җиңәрбез. Без Россиядә сан буенча икенче урында торабыз һәм без тырыш халык, милләт буларак үзебезне саклап кала алабыз. Бергә булганда, без көчле, – диде Рөстәм Миңнеханов утырышны тәмамлаганда.

Элек балачакта өлкәннәр янында утырган балаларны күрсәләр, «Бар, монда сүз урлап утырма», – дип куалап җибәрәләр иде. Утырыш башлануын көткәндә, телимме-теләмимме, үземә дә «сүз урлап» утырырга туры килде. Журналист икәнлегемне белдермичә, әңгәмәне сүзсез генә тыңлап утыру үземә дә ошады. Хәер, кемнең кайсы өлкәдән килүе дә, исем-фамилияләре дә мөһим түгел. Алар үзләрен зур милләтнең уллары дип саныйлар, һәм Татарстан алар өчен изге җир. Бу аларның һәр сөйләгән сүзләрендә, хәтта әйтми калган җөмләләрендә, уйларында, гамәлләрендә.

→ **Теманың дәвамы 4нче биттә.**

Кертемчеләргә яңа төр ярдәм әзерләнә

3 март көнне Үзәк банк «Татфондбанк», «Интехбанк», «Анкор Банк»ларның лицензияләрен алган иде. Шуннан бирле халыкның сораулары тынмый. «Татар-информ»да узган матбугат конференциясендә әлеге банк кертемчеләренә алга таба нишләргә кирәклеге турында сөйләштеләр.

Эльвира МОЗАФФАР

Илнар Тухбатов фотосы

Татарстанның икътисад министры Артем Здунов фикеренчә, хәзер төп бурыч – кертемнәре иминиятләштерелмәгән физик затларга, Татарстан эшмәкәрләренә банк кредиторлары реестрына эләгү. Бу банкта зыян күрүчеләр компенсация ала алсын өчен кирәк.

«Татарстанның эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» оешмасы генераль директоры Андрей Афонин моның өчен нишләргә кирәклеген дә аңлатты. «Татфондбанк», «Интехбанк» яки Иминиятләштерелгән кертемнәр агентлыгы сайтларына кереп, кредиторлар реестрына керү өчен язылырга торган гариза бланкын алырга һәм аны тутырырга кирәк. Бу гаризалар юридик, физик затлар, шәхси эшмәкәрләр өчен аерым. Гаризаны банкка тапшырганнан соң, аның язмышын гел сорашып торуың яхшы.

– Гадәттә, гариза 30 көн эчендә карала. Реестрга кертелү турында белешмә бирелгәч кенә тынычланырга була, – ди Андрей Афонин.

Банктан зыян күрүчеләр белән белгечләр көн саен Татарстанның сәүдә-сәнәгать палатасында очраша. Юстиция министры Лариса Глухова аңлатканча, биредә хезмәтләр бушлай башкарыла, аеруча «ТФБ Финанс» мәсьәләсе буенча ярдәм сорап килүчеләр күп икән. Инициатив төркем ярдәме белән «ТФБ Финанс» клиентларының хокуклары «Татфондбанк» кертемчеләренеке белән тигезләү максатыннан, 13 дәгъва гаризасы төзелгән. Һәркем суд аша үз хокукын үзе кире кайтарырга тиеш булачак. Татарстан прокуратурасы физик яктан мөмкинлекләре чикле ике клиентның эшен Вахитов районы судына юллаган. Эшләр 15 март көнне ябык режимда каралачак.

Татарстан хөкүмәте банк кертемчеләренә ничек тә ярдәм итү юлларын эзли. Шул рәвешле «Татфондбанк» клиентлары – юридик затлар өчен «Ташламалы лизинг» программасы гамәлгә кертелгән. Әлеге программаның төп максаты – кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышу. Программа буенча теләсә нинди мөлкәт өчен, 8 процент еллык ставка белән, биш елга кадәр финанс арендасы каралган.

Банклар белән бәйле вазгыятьтә алга таба «НОТА-Банк» мисалындагы чараны куллану фикере дә бар. Кертемчеләрнең инициатив төркеме Татарстан Президентына әлеге идея белән мөрәҗәгать иткән. Рөстәм Миңнеханов исеменнән Үзәк Банк адресына әлеге схеманы куллану мөмкинлеге турында мөрәҗәгать тә әзерләнгән. Схема зыян күргән банк кертемчеләрен үз канаты астына алырга әзер булган яңа банк табудан гыйбарәт. Шуңа риза булган банк физик затларның бер өлешен үзенә алачак. Алмашка ярдәм итәргә алынган банкка лицензиясе алынган оешмаларның билгеле бер активлары бирелә.

– Әмма күп нәрсә конкурс массасына, ягъни лицензиясе алынган банкларның мөлкәтенә бәйле, – ди Артем Здунов.

Акчалар беренче чиратта физик затларга, акчалары 1,4 миллион сумнан арткан кешеләргә биреләчәк. Икенче чиратта хезмәт хакы алмаган банк хезмәткәрләре, интеллектуаль милке өчен түләүләре булганнар ала. Калганнар өченче чиратка эләгә.

Ришвәтчелекнең тамыры тирән

Үткән җомгада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә республиканың ришвәтчелеккә каршы көрәш комиссиясе утырышын уздырды. Анда узган елга нәтиҗәләр ясалды һәм сүз 2017 елга планнар турында барды.

Узган ел Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм башка хокук саклау органнары тарафыннан коррупция юнәлешендәге 1038 җинаять эше ачыкланган. Шуларның 157се ришвәт алу белән бәйле. Китерелгән гомуми зыян 646 млн сум тәшкил итә. 323 кешегә карата җинаять эше ачылган. Мәсәлән, узган елның 22 сентябрендә «Балык Бистәсе» муниципаль унитар предприятиесе җитәкчесе өч елга ирегеннән мәхрүм ителгән. Аның законсыз рәвештә килешүләр эшләве аркасында, предприятие банкротлыкка чыккан.

Татарстанның Исәп-хисап палатасы тарафыннан 13 министрлык һәм ведомствода, республиканың 19 районында, 494 учреждение һәм оешмада контроль чаралар оештырылган. 74 җитәкче дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

– Җитәкчеләрнең шәхси кызыксынуын башлангыч этапта ук ачыкларга һәм каршылыклар килеп чыкмаслык итәргә кирәк. Узган ел нәтиҗәләре монда эшнең күп булуын күрсәтте. Хәтта министрлар арасында да керемнәр турында дөрес булмаган мәгълүматлар тапшыру ачыкланды, – диде Президент.

Татарстан Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең баш киңәшчесе Салават Рәхимов әйтүенчә, җир белән бәйле мәсьәләләрдә ришвәтчелек очраклары еш күзәтелә. Шундый төр закон бозуда 40тан артык авыл җирлеге башлыгының катнашы барлыгы ачыкланган.

Бу хакта Рөстәм Миңнеханов та әйтеп узды.

– Кайбер район башлыкларының җир кишәрлекләрен законсыз файдалануы билгеле булды. Шул ук вакытта аукцион процедуралары бозыла яки бөтенләй кулланылмый. Әбүлеп бирелгән кишәрлекләр максатчан файдаланырга өлгерми кала. Нәтиҗәдә җинаятьләр саны арта һәм социаль киеренкелек барлыкка килә. Бу очракта шунысына басым ясап әйтәм: һәр нәрсәне үзеңнән башларга кирәк, – диде Президент.

Татарстан Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең оештыру бүлеге мөдире Алексей Панкратов әйтүенчә, узган ел республиканың өч районында зур тикшерүләр булган. Балык Бистәсе, Биектау һәм Алексеевск районнарында коррупция белән бәйле закон бозу очракларының күп булуы ачыкланган.

– Җир кишәрлекләре мәсьәләсендәге кимчелекләрдән тыш, балалар бакчалары төзелеше вакытында закон бозу очраклары ачыкланды. Республикада мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен төзүгә бик күп акчалар бүлеп бирелә. Әмма соңрак бу өлкәдә акчаларны максатчан кулланмау, урлашу фактлары билгеле була. Мәсәлән, бер бакча куллануга тапшырылган. Ләкин ул эшли башлагач, шактый гына кимчелекләр булуы билгеле була. Янгын куркынычсызлыгына җавап бирми, мәсәлән. Аларны төзәтү өчен әти-әниләрдән акча җыюлар башлана. Шулай да Татарстан иң начар төбәк түгел. Ришвәтчелеккә каршы көрәш чаралары башка төбәкләрдә дә үрнәк итеп күрсәтелә, – ди ул.

Журналистларның: «Шулай да кайсы районда коррупция күбрәк?» – дигән соравын ул:

– Ришвәтчелек һәр җирдә дә бар, аерма шунда гына: кайдадыр ул күбрәк, ә кайдадыр азрак, – дип җаваплады.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

Дөнья чемпионатына турист карталары барлыкка киләчәк

Ростуризм башлыгы Олег Сафронов 2018 елда Футбол буенча дөнья чемпионаты уеннары үткән һәр шәһәрдә туристлар өчен махсус карталар ясарга тәкъдим итә, дип яза «Татар-информ».

Андый карталар берничә туристлар объектында булырга мөмкинлек бирә. Олег Сафронов «Кырымның кунак картасы»н мисалга китерде. Аның ярдәмендә ярымутрау кунакларына мәдәни һәм табигый объектларны карaганда ташлама ясала. «Без Футбол буенча дөнья чемпионаты узган шәһәрләрдә бу проектны чынга ашыруны сорыйбыз», – ди Сафронов. Ул ассызыклаганча, 2017 елда Конфедерация кубогы һәм 2018 елгы Дөнья чемпионаты узган шәһәрләрдә дөнья дәрәҗәсендә булырлык югары сыйфатлы инновацион турист эшләнмәләре ясалырга тиеш.

Искәртеп үтәбез, Конфедерация кубогы 17 июньнән 2 июльгә кадәр Мәскәү, Санкт-Петербургта, Сочи һәм Казанда үтәчәк.

Май бәйрәмнәренә өстәмә рейслар билгеләнгән

Быел май бәйрәмнәре вакытында, ягъни 27 апрельдән алып 10 майга кадәр, «Федераль пассажир компаниясе» ерак араларга йөрүче 240 өстәмә рейс билгеләгән. 28 апрельгә билетлар сатуга чыккан инде. Шуны да искә төшереп узарга кирәк, 2016 елның 11 декабреннән ерак араларга йөри торган поездларга билетлар сату 40 көн алдан түгел, ә 60 көн алдан башлана.

Өстәмә поездлар аеруча популяр маршрутлар буенча җибәреләчәк. Мәскәүдән Санкт-Петербургка, Костромага, Казанга, Новозыбковка, Чабаксарга, Саранскига, Белгородка, Льгов һәм Пензага. Шулай ук Санкт-Петербургтан Кировка, Волгоградка, Ижаугa, Казанга, Орелга, Ярославльга, Бөек Новгородка, Чабаксарга һәм башка шәһәрләргә.

Төбәкләргә пассажирлар агымының төп вакыты 28 апрель һәм 5 май көнне, кире юнәлештә 1 һәм 9 май көнне көтелә. Шул ук вакытта ихтыяҗ булса, билгеләнгән өстәмә поездлар саны тагын да арттырылырга мөмкин.

ШӘҺӘР ХУҖАЛЫГЫ

Бакчага асфальт юлдан

Моңа кадәр бакча дип бик исе китмәгәннәр дә быелдан җир кишәрлеге хәстәрен күрә башламагае әле. Чөнки нәкъ менә быелдан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов башлангычында, республикадагы бакчачылык ширкәтләренә асфальт юллар төзү старт ала.

Автор фотоархивыннан

Казанда тәүге чиратта «Энергетик», «Строитель», «Геолог», «Мечта», «Любитель природы», «Волга» һәм «Полуостровок»ка бәхет елмаячак. Әлеге ширкәтләр 5315 кишәрлекне берләштерә.

– Бакчачылык ширкәтләренә илтә торган юллар СССР чорларыннан бирле каралмады. Татарстан Президенты ярдәмендә мәсьәләне чишү мөмкинлеге туды. Безнең халык бакчада эшләргә ярата бит, – дип фикере белән уртаклашты Казан муниципаль берәмлеге башлыгының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Куляжев чыгышында әйтелгәнчә, киләсе җәйдә башкаланың 33 урам юлы, 180 ишегалды, 30 квартал эче юллары салына. Ибраһимов, Копылов, Маршал Чуйков, Восстание, Тукай, Миль, Карл Маркс, Даурия, Танк, Нариманов урамнары юллары төзекләндерелә. Транспорт аварияләре еш күзәтелә торган Беломор белән Чапаев урамнары һәм Фучик белән Сафиуллин урамнары киселешендә светофорлар, рәшәткәләр урнаштырылачак.

«Имин һәм сыйфатлы юллар» федераль проекты кысаларында, быел Казан юлларын яңартуга ике миллиард сум тәгаенләнгән. Шуның 1,2 миллиард сумы – федераль, ә 800 миллион сумы – республика бюджетыннан.

– Казанның муниципаль юл фондыннан 94 миллион сум билгеләнде. Бу акчаларга 46 мең квадрат метр юлның чокыр-чакырларын ремонтлауга керешелде. Эш күбесенчә төнге сәгатьләрдә үткәрелә. Моннан тыш, 320 юл билгесе куелачак, тагын өч километр рәшәткә тотылачак, – диде Игорь Куляжев.

Төзекләндереләчәк ишегалларыннан иң зурлары: Академик Павлов урамындагы 19,21, 23, 23а; Голубятников урамындагы 30нчы, Дубравная урамындагы 23, 23а, 23в, 25нче; Восход урамындагы 11, 13, 15нче; Блюхер урамындагы 81, 83, 85нче; Минск урамындагы 44, 46, 48, 52нче; Себер трактындагы 24, 26, 28, 30, 32нче йортлар.

– Ишегалларындагы юллар киңәйтелә. Өч мең машинага «кесә», ягъни урын барлыкка киләчәк. Төзекләндерү эшләре физик мөмкинлекләре чикле кешеләрнең мәнфәгатьләрен исәпкә алып үткәрелә, – диде Игорь Куляжев.

Казанда 2011 елдан башлап 1625 ишегалды, 10 миллион квадрат метр юл өслеге, шул исәптән 36 бистәдәге 263 юл төзекләндерелгән.

– Чиктән тыш ватылып беткән ишегаллары юллары төзекләндерүнең быелгы планына кертелде. Эш колачы зур әле, шулай да һәммә ишегалдына барып җитәчәкбез. Салмачы бистәсендә яшәүчеләр Кол Гали урамы юлыннан зарлана. Быел, ниһаять, Кол Гали урамы юлы киңәйтеп салыначак, анда светофорлар да булачак, – дип, сөйләшүгә йомгак ясады Рөстәм Нигъмәтуллин.

Дамир БӘДРИЕВ.

ЮГАРЫ БЕЛЕМ: КФУ

Узган атнада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан (Идел буе) федераль университеты Попечительләр советы белән очрашты. Әлеге очрашу барышында Президент уку йортының кайбер биналары белән танышты, ә университет ректоры Илшат Гафуров Экология һәм табигатьне саклау министрлыгы һәм республиканың башка предприятиеләре белән килешү төзеде.

Нинди үзгәреш көтелә?

Килешү нигезендә, Экология министрлыгы белән университет табигатьне саклау һәм республиканың экологик чисталыгын тәэмин итүдә үзара хезмәттәшлек итәчәк.

Төп тема Казан федераль университетының фәнни-мәгариф комплексын үстерү мәсьәләсе булды. Кайчандыр зур гауга чыгарып, университетта татар филологиясен ябып йөргән Илшат Гафуров быел Президент алдында яңадан татар теле һәм әдәбияты үзәген булдыру турында сүз кузгатты. Ул Каюм Насыйри институтының «Татаристика» бүлегендә гамәлгә ашырылачак.

– Югары квалификацияле милли кадрлар әзерләү – университетның төп бурычларының берсе. Иң беренче чиратта без татар теле, тарихы, әдәбиятына кагылышлы мәсьәләләрне чишәргә тиеш, – диде Илшат Гафуров.

Ректор сүзләренчә, «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен саклау, өйрәнү, үстерү» дигән дәүләт программасын үтәү һәрвакыт акча мәсьәләсенә барып терәлә. Бу программаны тормышка ашыруга юнәлтелгән финанслар 2015 елда – 11,16 миллион, 2016 елда – 12 миллион, 2017 елда 21,08 миллион сумга кыскартылган.

Шулай ук Илшат Гафуров Президенттан укытучы кадрларны яңадан укыту үзәге ачуга булышлык күрсәтүен сорады. Үзәк Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының хәзерге вакытта буш торган бишенче бинасында (Сул як Болак, 34) эшләячәк. Бинага 150 миллион сумлык ремонт кирәк.

Рөстәм Миңнеханов та укытучыларны яңадан әзерләү, квалификацияләрен арттыру мөһим мәсьәләләрнең берсе булуын искәртте.

– Бүген дөнья дүртенче сәнәгый революция алдында тора. Без – күренекле технологик үзгәреш шаһитлары. Әлеге процесслар, үз чиратларында, яңа таләпләр куя. Бу таләпләргә төрле өлкәләрдә әзер булырга кирәк, шул исәптән мәгариф өлкәсендә дә. Шуңа күрә укытучыларны яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен арттыру темасы аеруча әһәмиятле, – диде Президент.

Университетның «ректор йорты»нда да үзгәрешләр көтелә. Биредә танылган рус галиме Николай Лобачевский музеен булдырырга уйлыйлар.

– Музей хәтер сагында торудан тыш, мәктәп укучылары, студентлар өчен кызыклы булган фәнни белем бирү мәйданчыгы да, – диде Илшат Гафуров.

2018 ел исә КФУда Толстой елы буларак билгеләп үтеләчәк. Ә елның төп вакыйгасы – Лев Толстой исемендәге халыкара премия (рус әдәбияты буенча) булачак.

Алисә САБИРОВА.

Дөньякүләм танылу

Күпләребезнең яшьлек хыялларын тормышка ашыруда зур роль уйнаган Казан дәүләт университетының (хәзер Казан федераль университеты) дөнья университетлары арасында да абруе зур. Британиянең ирекле һәм абруйлы басмасы Quacquarelli Symonds(QS) дөньяның 4 меңнән артык иң яхшы университетларын тикшереп, 2016 елгы нәтиҗәләрне игълан итте.

Нәтиҗә университетларның белем бирү системасын, фәннәрне үстерүдәге өлешен һәм башка күрсәткечләрне исәпкә алып ясалган. Безнең Казан федераль университеты фәннәр рейтингында сигез юнәлештә (лингвистика; мәгълумат фәннәре һәм журналистика; археология; инглиз теле һәм әдәбияты; мәгариф; экономика һәм эконометрика; физика һәм астрономия; химия) буенча беренче 500леккә кергән.

«Татмедиа» мәгълумат агентлыгында узган матбугат конференциясендә Казан федераль университеты ректоры Илшат Гафуров һәм әлеге вузның проректоры Марат Гарифуллин журналистларга бу яңалыкны горурланып җиткерделәр.

– Без мондый рейтинглар бәйгесендә өченче ел гына катнашабыз әле. Беренче елны беренче 500леккә керә алмадык. Быел уңышларыбыз шактый. Бу бит университетыбызның абруе дөнья күләмендә дә күтәрелүе турында сөйли. Мондый уку йортының дипломлы белгечләренә ихтыяҗ да зур булачак. Ә бу аларга яхшы эш табуны җиңеләйтәчәк.

18 институтны берләштергән, хезмәткәрләренең саны гына да 11 меңнән артып киткән галимнәр һәм студентлар армиясен дөнья күләмендә таныту җиңел эш түгел, билгеле. Ләкин җитәкчеләр әйтүенчә, Казан вузында алдагы елларда күп кенә юнәлешләр буенча беренче 100леккә керер өчен барлык шартлар да җитәрлек.

– Университетта яшьләргә зур игътибар бирелә. Күп кенә танылган галимнәрнең яше 20-35 арасында. Аларның үзләренә лабораторияләр бирәбез, хәтта җитәкче органнарга сайланырга мөмкинлек тудырабыз, – диде ректор.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Татар авыллары эшмәкәрләре җыенында катнашучыларның берәр авылга барып, андагы җирле эшмәкәрләрнең эшчәнлеге белән танышуы традициягә керде. Узган елларда делегатлар Мамадыш, Кукмара, Теләче районнарына барган булса, быел алар Балтач һәм Арча районнарында булып кайтты.

«АВЫЛНЫ ФЕРМЕРЛАР ЯШӘТӘ»

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Фотолар: baltasi.ru, baltach.ru

БАЛТАЧ УҢГАННАРЫ

Балтачта тырыш, һөнәрле, булдыклы халык яши. Районның Бөрбаш авылына килеп керүгә, автобустагы бертөркем кеше, биредә уңган халык яшәгәне күренеп тора, капкалары нык, йортлары төзек, тормышлары бөтен, дип әйтеп куйды. Озата баручы: «Бөрбаш ул – Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның туган авылы да», – дигәч, кунакларның кызыксынуы тагын да артты.

Бөрбашта күптән түгел генә казылык ясау цехы ачылган. Илшат Гыйльмуллинның әлеге бизнесы кечкенә генә ыслау җайланмасыннан башланган. Баштарак казылыкны үзләре өчен генә ясаганнар. Моны белеп алган авылдашлары да казылык ясап бирүен сорап килә башлый. Шуннан Илшат аерым цех ачарга ниятли. Бүген ул цех тулы көченә эшли. Монда ел әйләнәсе сыер, ат, каз, үрдәк, тавык ите ыслана, казылык, колбаса, бастырма ясала. Халык үз хуҗалыгында үстерелгән сыер яки атын бирегә алып килә дә казылык ясатып ала, ягъни бер килограммы 85 сумнан әзер продукция сатып ала. Илшат үзенә ясыйсы продукция өчен атны шәхси хуҗалыклардан сатып ала да сугым цехында эшкәрттереп алып кайта. Казылык ясау цехында бүген көненә 150 кг продукция җитештерелә. Шәхси хуҗалыклардан җыелган заказлары да күп. Ай ярым алдан чират алып куючылар да бар икән.

Бөрбаш авылында агач эшкәртү цехы да эшли. Аның хуҗасы Булат Фазлыев та авылдашларын эшле иткән. Бүген аның кул астында биш кеше эшли. Цехта юкә агачыннан мунча ишекләре, вагонкалар, агач материалыннан башка кирәк-яраклар эшләнә. Төзелеш өчен төрле улчәмдә агач материаллары әзерләнә. Булатның әйтүенә караганда, биредә көненә 3-4 кубометр агач эшкәртелә. Агач чүбе дә тик ятмый. Бердән, цех шул опилка белән җылытыла, икенчедән, тушәмне җылыту өчен чормага салырга дип, халык та сорап килә икән.

Казылык ясау цехы Балтачта берничә. Татар эшмәкәрләре җыенында катнашучылар Рәмзия Закированың крестьян-фермер хуҗалыгында да булды. Эш башлаганда ул, башлангыч капитал буларак эш башлаучы фермерларга ярдәм итү программасы нигезендә, 1,5 млн сум акча алган. Фермасында атлар, сарыклар үрчетелә. Ит эшкәртү цехы эшли, казылык ясала, каз ыслана, итле ярымфабрикатлар җитештерелә. Моннан тыш, фермер хуҗалыгыннан продукция көн саен районның мәктәп һәм балалар бакчасына озатыла. Әмма моның кадәр продукция өчен итне үзләре генә җитештереп бетерә алмый, сатып та алырга туры килә. Фермер хуҗалыгының үзенең кафесы һәм кибете дә бар.

Соңрак делегатлар алдында чыгыш ясаган Балтач муниципаль районы башлыгы Рамил Нотфуллин сүзләренчә, яшәешнең тотрыклылыгы, кешеләрнең алдагы көнгә ышанычы җитештерү тармакларындагы нәтиҗәле эшчәнлек белән бәйле.

– Районда эшмәкәрлекне тагын да киңрәк җәелдерү буенча алда зур бурычлар тора. Фермер хуҗалыклары, иң беренче чиратта, авыл халкын эш белән тәэмин итә. Шәхси ярдәмчел хуҗалыклар да район икътисадындагы иң мөһим тармак булып тора. Шул уңайдан шәхси хуҗалыклар ташламалы бәядән терлек азыгы белән тәэмин ителә. Терлек санын саклап калу өчен төрле субсидияләр бирелә. Узган ел 25 млн сумга төрле формада ярдәм күрсәтелде, – диде ул.

«ТАТАРСТАНГА КҮЧЕП КИЛӘМ»

«Сездә халык шәп яши. Җитәкчелек тә халык турында кайгырта. Фермерларга Татарстандагы кебек ярдәм башка беркайда да юк». Район белән танышу барышында чит төбәкләрдән килгән кунаклар авызыннан бу сүзләрне еш ишетергә туры килде. Чиләбедән килгән Дамир Абдуловның Татарстанга беренче генә килүе.

– Кичәге көннән бирле бер уй тынгылык бирми миңа. Татарстанга күчеп килергәме әллә дип торам әле, – дип башлады ул сүзен. – Монда миңа кешеләр, алар белән аралашу ошады. Казан бик матур, чиста шәһәр. Чынлап әйтәм, башка дөньяга эләккән кебек мин.

Аның юлдашы Рәис Габидуллин да шундый фикердә. Узган елны Теләче районына барып кайткач, тормыш иптәше дә Татарстанга күчеп килү турында хыяллана башлаган.

– Миңа биредә иң ошаганы шул: сездә дәүләт ярдәмен беренче булып инвесторларга түгел, крестьян-фермер хуҗалыкларына бирәләр. Авылны шул фермер хуҗалыклары яшәтә бит. Инвестор килә дә китә. Ә фермер үз авылында яши, эшли, авылын күтәрергә булыша, авылдашларын да эшле итә. Илне – авыллар, ә авылларны фермерлар яшәтә. Татар авылларының киләчәге нәкъ менә эшмәкәрлекнең уңышына бәйле, – ди Рәис Габидуллин.

Аның сүзләрен Удмуртиянең Кияс районы Таужамал авылыннан килгән Фердинант Мәҗитов та куәтли.

– Яшьләр башта шәһәргә китәләр дә, анда яшәү авыр дип, авылга кире кайталар. Ике егет шалтыратып, авылга кайтсак, сездә эш булмасмы, дип әле яңарак кына сорады. Эш табылса, алар кире кайтачак. Димәк, эш урыннары кирәк. Татарстанда шәхси хуҗалыклар күчле эшләп килә. 20шәр баш сыер тотучылар да бар, диләр. Безнең яшьләр менә шул эшкә керешеп китә алмый әлегә, югыйсә бозаулар бирәбез, үстерегез дип тә әйтеп карадык. Татарстанда ярдәмче хуҗалыкларда сөт җитештерүче кешеләргә мини-ферма төзү өчен ярдәм дә күрсәтелә икән. Терлекчелек фермаларына юл салу программасы да эшләп килә сездә. Эшлә генә, хөкүмәт булышырга әзер, – ди ул.

Фердинант элек комбайн, тракторларны арендага биреп акча эшләгән булса, бүген ул эшчәнлек төрен үзгәрткән – терлекчелек белән шөгыльләнә башлаган. Биш миллион сум күләмендә грант алып, 100 баш сыерга ферма төзеткән, терлек сатып алган. Яңарак кына тагын бер ферма эшләткән. Хәзер аның 150 баш савым сыеры бар. Авылдагы 11 кешене эшле иткән. Татар авыллары эшмәкәрләре җыенына ул ел да килә икән.

– Мин монда аралашырга, яңа кешеләр белән танышырга, тәҗрибә тупларга, киңәшләшергә киләм. Кая чакырсалар да, барырга тырышам. Бер урында туктап торырга ярамый, – дип, куен кесәсеннән блокнотын чыгарып, үзе өчен нәрсәдер теркәп тә куя ул.

Самара өлкәсенең данлыклы Гали авылыннан килгән Халит Йосыпов та бер көн эчендә дүрт кеше белән танышып, телефон номерларын алышуларын әйтте.

–Мондый җыеннарда мин татар булуым белән кат-кат горурланам. Тырыш, булдыклы кешеләрне күреп сокланам. Кайсы Президентның Рөстәм Миңнеханов кебек шулай ватандашларын җыеп сөйләшкәне бар, – ди ул.

Марина Пичугина укучыларга химия дәресе бирә.

Автор фотолары

Мәктәп укучылары вертолет төзи

Кайчандыр гуманитар юнәлештә белем биргән Казанның 8нче гимназиясе хәзер булачак инженерларга исәп тота. Инженерларның да ниндиләре генә әле: турыдан-туры заводта вертолет төзи алганнары!

Алисә САБИРОВА

Беренче карашка гимназиядә гап-гади балалар укый. Белем йорты да башкалардан әллә ни аерылмый, ләкин Казан вертолет заводының генераль директоры Вадим Лигай нәкъ менә бу уку йортына зур өметләр баглый. Ни өченме? Моннан сигез ел элек ул гимназиядә «вертолет сыйныфы»н ачып җибәрә. Бирегә укучыларны IX сыйныфтан соң тапшырылган имтиханнары нәтиҗәсендә кабул итәләр. Төп игътибар, әлбәттә, математика белән физикага бирелә.

Вадим Лигай завод җитәкчесе булгач, кадрлар кытлыгына юлыга. Олы яшьтәге тәҗрибәле белгечләрне алмаштырырлык яшьләр җитми. Булганнарының да белем дәрәҗәсе хәтта мәктәп программасын тартмый. Кайчандыр үзе дә заводта инженер-конструктор, технолог булып эшләгән Вадим Лигай югары дәрәҗәдәге белгечләрне мәктәптән үк әзерләргә кирәклеген шул вакытта аңлый.

– Вадим Александрович безнең гимназиягә шундый тәкъдим белән килгәндә, мин мәктәп директоры булып эшли генә башлаган идем. Аның бу тәкъдимен сөенеп кабул иттек. Булачак инженерларны әзерләү уен эш түгел. Физика, математика фәннәренең сәгатьләрен арттырдык. Хәзер безнең мәктәп районда БДИ нәтиҗәләре буенча әлеге фәннәрдән алдынгы урында тора, – ди Марина Пичугина.

«Вертолет сыйныфы»ның беренче чыгарылышы 2012 елда була. 28 укучыдан 18е Казан авиация институтына (КНИТУ-КАИ) укырга керә. Шуларның бишесе хәзерге вакытта инде Казан вертолет заводында эшли.

– Бер караганда, биш кеше бик аз сыман, ләкин бу – яхшы күрсәткеч. «Вертолет сыйныфы»н тәмамлаган бер генә укучыбыз да югалып калмады. Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләрендәге иң яхшы уку йортларында белем алалар. Вертолет заводына эшкә керү шулай ук җиңелләрдән түгел. Эшкә тотынганчы, яшь белгечләрне бик җентекләп тикшерәләр, зур конкурс үткәрәләр, – диде Марина Пичугина.

«Вертолет сыйныфы»н тәмамлаган укучылар илнең теләсә кайсы вузына укырга керә ала. Ә тормышларын инженер һөнәре белән бәйләргә теләүчеләргә вертолет заводы төрле яктан ярдәм итә. Әйтик, КАИга укырга кергән һәр студентка генераль директор үз куллары белән ноутбук тапшыра. Вуз тәмамлаган белгеч исә заводта эш белән тәэмин ителә. Укучылар өчен чыгарылыш кичәсен дә Вадим Лигай вертолет заводы цехында оештыра. Өлгергәнлек аттестаты да аларга республиканың иң дәрәҗәле белгечләре алдында тапшырыла.

Гимназиядә белем бирү практик дәресләр белән үрелеп бара. Дәресләрнең иң кызык, иң мәгълүматлы өлеше дә вертолет заводында башлана. XI сыйныф укучысы Арина Перевезенсева да заводта узган дәрестән соң вертолетларга гашыйк булган. Киләчәген инженер һөнәре белән бәйләргә ниятли кыз.

– Мин кая укырга керергә дип озак уйладым. Ахыр чиктә имтихан өчен физиканы сайладым. Башка сыйныфлар белән чагыштырганда, бездә укуы кызыграк. Хәзерге вакытта максатчан рәвештә КАИга укырга керергә җыенам. Заводта иң ошаганы конструкторлык бюросына экскурсия булды. Кызык бит: безнең күз алдыбызда әр-яңа вертолетлар уйлап чыгаралар! Бөтен дөньяда киң кулланышта булган «Ансат» вертолеты да монда «туган». Киләчәктә үземнең дә яңа вертолетлар уйлап табасым килә, – ди Арина.

Николай Хаҗиев белән Арина Перевезенсева.

Вертолетта очып карамаган кеше яхшы инженер була алмый. Арина да сыйныфташы Николай Хаҗиев белән заводта Ми-17 вертолет тренажерында очу нигезләрен өйрәнә.

– Мин андый ук хисләр кичерермен дип уйламадым. Тренажер гына булса да, үзеңне чын вертолет йөрткән кебек хис итәсең. Биредә бар әйбер дә чын вертолетныкы кебек эшләнгән, – ди Арина.

Арина белән Николай үзләрен бары тик тәҗрибәле белгечләр өчен генә оештырыла торган «Технопрорыв» бәйгесендә дә сынап карарга өлгергән.

– Биредә вертолет заводының иң яхшы белгечләре катнашты. Командаларга бүленеп, идеаль оешма уйлап чыгардык. Заводта эшләүче белгечләр белән өч көн дәвамында аралашу инженер булырга дигән максатымны тагын да ныгытты, – ди Николай.

Башка мәктәпләрдә сызым дәресләре бетерелгән вакытта «вертолет сыйныфы»нда ул төп фәннәрнең берсе буларак укытыла. «Компьютерда вертолет сызымнарын ясаганчы, башта үзеңне кәгазьдә сынап карарга кирәк», – диләр укучылар. Бу тәҗрибә аларга КАИда белем алганда да ярдәм итә. Институтта уку, нигездә, шул сызымнардан тора да бит инде. Югары белем алганда, «вертолет сыйныфы» укучыларына завод стипендияне үзе түли.

Гомумән, «вертолет сыйныфы» – заводның киләчәккә юнәлтелгән иң уңышлы проектларының берсе. Һәр укучы Вадим Лигайны үз остазы буларак кабул итә, аның кебек булырга тырыша. Җитәкче дә балаларга игътибарын кызганмый. Белем көне, Соңгы кыңгырау бәйрәмнәре Вадим Лигайдан башка узмый.

Хирурглар җитми

Республика клиник хастаханәсендә хирургия өлкәсендәге узган елгы эшчәнлеккә нәтиҗә ясалды, киләсе елга бурычлар билгеләнде.

Татарстанда 81 медицина учреждениесендә хирургия ярдәме күрсәтелә. Бу өлкәдә дөрес оештырылган эшчәнлек 2016 елда ашкайнату белән бәйле авырулардан үлүчеләр санын 20,1 процентка киметергә ярдәм иткән. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш белгече, хирург Андрей Анисимов әйтүенчә, былтыргы елның төп нәтиҗәсе дә хирургиягә кагылышлы авырулардан үлүчеләр санын киметә алу.

– Хирургның көндәлек төп эше – сукыр эчәк, ашказаны җәрәхәте һәм башка шундый операцияләрдән гыйбарәт. Шул ук вакытта республиканың 15 медицина учреждениесендә, югары технологияләр кулланып, хирургиягә кагылышлы башка катлаулы авыруларны да дәвалыйлар. Татарстанда биш әйдәп баручы клиника федераль бирем нигезендә эшли: Казанда урнашкан Республика клиник хастаханәсе, Республика балалар клиник хастаханәсе, Төбәкара клиник-диагностика үзәге, Онкология диспансеры, Чаллыдагы ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсендә йөрәк-кан тамырлары системасына, травматология, ортопедия буенча һәм башка операцияләр башкаралар, – ди Андрей Анисимов.

Табиб сүзләренчә, былтыр 21 215 пациентка югары технологияле медицина ярдәме күрсәтелгән. Меңнән артык авыруны федераль клиникаларда дәвалау мөмкинлеге тудырылган. Былтыр бөер күчереп утырту буенча 19 операция ясалган. Андрей Анисимов бу төр операцияне Татарстан өчен эксклюзив дип атый.

Хирургия өлкәсендә чишәсе проблемалар да җитәрлек. Вакытында белгечләргә мөрәҗәгать итмәү аркасында үлемгә китергән иң төп авырулар булып ашкайнату органнары системасы авырулары, аппендицит, кискен холецистит, ашказаны-эчәктәге кан китүләр, бөсер чыгу һәм башкалар санала.

Шулай ук кадрлар кытлыгы да сизелә. Бүген республикада 463 хирургия белгече бар. 14лəп районда хирурглар җитми. Бу проблеманы торак мәсьәләсен яхшырту, башка төрле программалар ярдәмендә чишәргә омтылалар.

Сүз уңаеннан, Татарстан хирурглары 4-7 апрельдә Мәскәүдә узачак Милләтара хирургия конгрессына әзерләнә. Анда хирургия өлкәсендәге мәсьәләләр турында сөйләшәчәкләр.

Эльвира МОЗАФФАР.

ТАМОЖНЯ

КЫЗЫКМА КАРАЧКЫГА

Узган елгы эш нәтиҗәләре буенча Татарстан таможнясы Россия Федерациясе күләмендә «Эчке таможняның иң яхшы коллективы» номинациясендә беренче урынга лаек булган.

Дамир БӘДРИЕВ

airportrn.ru

– 30 елга тәүге мәртәбә ялланган җиңү бу. Әлбәттә, хезмәт күрсәткечләребез дә яхшы, – дип, сөенечләре белән уртаклашты Татарстан таможнясы җитәкчесе Альберт Мавликов «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә. – Федераль бюджетка узган ел 24 миллиард сум таможня җыемы керттек.

Татарстанның 995 юридик һәм физик заты узган ел 121 ил белән икътисади эшчәнлек алып барган. Товарлар зур партияләрдә Һиндстанга, Польшага, Венгриягә, Украинага һәм Кытайга чыгарылган. Республика үзе исә Германиядән, Кытайдан, АКШтан, Төркиядән, Италиядән күпләп товар кертә. Быел тышкы икътисади эшчәнлектәге активлар сафына Куба белән Канада да кушылган.

«Казан» халыкара аэропортында быелның ике аенда 53 697 пассажирга хезмәт күрсәтелгән. Апрельдән airBaltic авиакомпаниясе Рига – Казан – Рига даими рейсларын башлый. Март аенда Таиландның Утапао шәһәренә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Әль-Мактум, Төркиянең Анталия шәһәренә чартер рейслары башлана.

– Испаниягә, Грециягә, Кипрга авиарейслар ачу планлаштырыла. Быел булачак Конфедерация кубогы, шулай ук футбол буенча 2018 елда узачак Дөнья чемпионаты пассажирлар агымын нык арттырачак, – диде Альберт Мавликов.

Татарстан таможнясы үз эшчәнлекләренә электрон технологияләрне актив рәвештә кулланышка кертә. Хезмәткәр тарафыннан товарга декларация әзерләү уртача ике сәгать дәвамында башкарылса, автомат-электрон тәртиптәге декларация тутыруга 2-3 минут та җитә.

Росфиннадзор хезмәте бетерелү сәбәпле, 2016 елдан башлап чик аша акча-валюта әйләнешен таможня хезмәте күзәтчелектә тота.

– Россиягә чик аша кергәндә яки башка илләргә чыкканда акчаң 10 мең доллардан артса, ул таможня декларациясендә күрсәтелергә тиеш. Шушы таләпне үтәмәгән өчен, быелның ике аенда 15 административ эш кузгатылды. Салкын корал йөртү, рөхсәт ителгән күләмнән күбрәк итеп исерткеч эчемлек алып чыгу яки алып керү, наркотиклар ташу тыела. Җәнлек, кош карачкыларын чик аша йөртергә рөхсәт юк. Мәсәлән, крокодил карачкысы, документлары булмаганы өчен, физик заттан конфискацияләнеп, федераль университет музеена тапшырылды, – дип белдерде таможня хезмәте генерал-майоры Альберт Мавликов.

Интернет-кибет белән эш йөрткән очракларда, аеруча Кытай форумнарында сак булу зарур. «Ябыгу өчен» диелгән чәйдә, кофеда һәм фитнес белән шөгыльләнгәндә кулланыла торган продуктларда көчле тәэсирле химик матдәләр булуы ихтимал. Шифр ясау (криптография) мөмкинлегенә ия мобиль телефоннарны, смартфоннарны, планшет компьютерларны, ноутбукларны һәм башка техник җайланмаларны интернет-кибет аша кайтартырга, заказ бирергә ярамый. Россиядә кайсы модельләрдәге электрон товарларга рөхсәт булуын Евразия икътисади комиссиясенең бердәм нотификация реестрыннан карарга була.

Евразия икътисади берлегенең Таможня кодексы быелның 1 июлендә гамәлгә куелыр дип көтелә. Евразия икътисади берлегенә Россия, Белоруссия, Казахстан һәм Кыргызстан керә.

СОРАУ-ҖАВАП

Хатыным пенсиядә булса да эшли. 1 апрельдән эштән китәргә уйлый. Эшләмәүче пенсионерларның акчалары артты бит, аңа да арттырачаклармы? Бу нинди тәртиптә башкарыла? Узган елгы индексацияне исәпкә алачаклармы?

В.САФИН,
Казан.

Вахитов районы пенсия бүлеге белгечләре аңлатуынча, пенсионер эштән киткән очракта, ул индексацияләнгән пенсиясен өч айдан соң алырга хаклы. Әгәр хатыныгыз 1 апрельдән эштән китәргә уйлый икән, бу очракта аңа мартның соңгы эш көнендә эштән китү турында гариза тапшырса уңышлырак. 31 мартта эштән китсә, оешма Пенсия фондына 15 майга кадәр мәгълүматларны тапшырачак, анда хатыныгызның апрель аенда эшләмәгәне күренә. Башланмаган айның бер эш көне дә индексацияләнгән пенсия алу вакытын чигерә. Әйтик, 1 апрельдән эштән киткән очракта, пенсияне бары 1 августта гына арттырып бирәчәкләр. Июньдә пенсияләрне 2016-2017 ел өчен дә индексацияләү турында карар кабул ителергә тиеш. Хатыныгыз 1 июльдән индексацияләнгән пенсия алачак.

Конфедерация Кубогы FIFA-2017гә җанатар паспорты кирәк, диләр. Аны кайдан алырга була?

Булат КӘРИМОВ,
Чаллы.

Халыкара турнир матчларына кергәндә, билеттан тыш, барлык тамашачылардан да җанатар паспортын сораячаклар. Казанда шундый Үзәк Бауман ур., 44/8 («Родина» сәүдә-күңел ачу комплексы) адресы буенча урнашкан. Дүшәмбедән җомгага кадәр эш сәгатьләре – 11.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр (тәнәфессез), шимбә – 11.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр (тәнәфессез). Җанатар паспорты турындагы тулырак мәгълүматны fan-id.ru сайтыннан алырга була.

Нияз Халитов:
«Сөембикә каберен инде табып булмый»

Нишләп безнең Чыңгыз тамырыннан килгән хан сөякләре кайдадыр тузан җыеп ята? Архитектор-реставратор, архитектура тарихчысы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Нияз Халитов әлеге теманы совет чорында ук кузгаткан булган.

Бик күп гыйльми, тарихи эчтәлектәге китаплар авторы Нияз аганың быел сигез хезмәте Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде.

tatar-inform.ru

– Тарихчы буларак, ханнарыбыз сөякләре язмышы мине гел борчый. Минем өчен бу – бик кызыклы тема, – ди галим. – Чыннан да, бу турыда җәмгыятьтә беренче булып аваз салдым шул. Совет дәверендә үк шушы мәсьәләгә юнәлеш тоткан идем. Бер зур җыелышта Альфред Халиковтан: «Нишләп безнең Чыңгыз тамырыннан килгән хан сөякләре кайдадыр тузан җыеп ята?» – дип сорадым. Археология бүлеге җитәкчесе буларак, бу сорау аңа бик ошап бетмәгән иде. «Барысы да тәртиптә, тиешле, ышанычлы урында саклана. Вакыты җиткәч, хәл итәрбез», – дип җавап кайтарды ул. Җавап мине канәгатьләндермәде. Бу теманы алга таба да кузгата башладым. «Молодежь Татарстана» газетасына зур мәкалә яздым. Фикерләр төрле булды. Сөембикә манарасы янына мавзолей төзергә тәкъдим иттем. Рөстәм Зәбиров бик яхшы проект ясады. Каберләрнең берсе – Мөхәммәтәминнеке, тагын берсе – Мәхмүтнеке диган фаразлар бар. Моны нечек ачыкларга – мин анысын аңламыйм. Әмма аларның безнең ханнар икәне төгәл билгеле. Алар тиешенчә җирләнергә лаек. Бөек Чыңгызыйларның пантеоны булырга тиеш! Касыйм шәһәреннән Сөембикәне эзләп табып, монда күчереп күмәргә теләүчеләр дә бар. Бу инде – авантюра. Аны табып булмый. Касыймда кыл да кыймылдамаган. Иске зират бөтенләй беткән, эзләре дә калмаган. Сөембикәнең җәсәден каян эзләргә? Шаһгали төрбәсендә ул юк. Сөембикә кайдадыр башка җирдә дәфен ителгән. Ханнарыбызның каберләрен барларга кирәк, анысы бәхәссез, – ди ул «Татар-информ»га биргән әңгәмәсендә.

Шушы көннәрдә Татарстан Дәүләт Советында Рәшит Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале Попечительләр советының беренче утырышы үтте. Хәер, аның составына керүчеләр Попечительләр советын, үзебезчә татарчалаштырып, Кайгыртучылар советы дип атадылар. Аның рәисе итеп Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев сайланды. Аның советына Дәүләт Советы депутатлары, фән һәм мәдәният эшлеклеләре белән бергә матбугат чаралары җитәкчеләре, шул исәптән «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Гөлнара Сабирова да керде.

Аз да җитә, күп тә бетәме?

Зөһрә САДЫЙКОВА

ФЕСТИВАЛЬГӘ БИНА КИРӘК

13 ел дәвамында үзе генә эшләп килгән фестивальнең Кайгыртучылар советын булдыру идеясе болай гына барлыкка килмәгән анысы. Фестивальләр күбәеп, көндәшлек арткан вакытта, эшләр һәм яшәр өчен шартлар да үзгәрүе – гадәти күренеш. Дәүләти дәрәҗәгә күтәрелгән әлеге җыр фестиваленең чыгымнары да арта, димәк, оештыручылар тагын да зуррак ярдәмгә өметләнә. Проектның авторы һәм җитәкчесе, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рифат Фәттахов әйтүенчә, бүгенге көндә фестивальнең бюджеты – 9 млн 850 мең. Әмма елына 22 чара оештырган оешма өчен бу акчалар аз, чөнки бер концертны үткәрер өчен 620 мең сум да җитми. Мәсәлән, күптән түгел генә филармония концертлар залында яшь һәм өметле җырчы Азат Абитовның концертлары тулы заллар белән узды. Моның өчен фестиваль бюджетыннан 960 мең сум акча тотылган, шуның 200 меңнән артыгы – реклама өчен. Дөрес, фондның, дәүләттән алынган ярдәменнән тыш, иганәчеләре дә бар.

Татар музыка сәнгатен зурлауга, күтәрүгә зур өлеш керткән фестивальнең үз бинасы булмау да иң зур проблемаларның берсе булып тора. Бу репетицияләрне тиешле дәрәҗәдә алып барырга комачаулык итә. Россия башкаласы кунагы – матбугат чаралары белән эшләүче тулы вәкаләтле вәкил урынбасары Азат Әхтәриев Мәскәү татарларына бина бирелүен шатланып җиткергәннән соң, утырышта катнашучылардан: «Әнә мәскәүлеләр булдырган бит, ни өчен безнеке килеп чыкмаска тиеш әле?» – дигән фикер яңгырады. Әмма бина юк, дип кул кушырып утыра торганнардан түгел алар. Моңа кадәр эшләгәннәр, алга таба да фестивальнең планнары зурдан. Шуларның берсе – өч елга бер тапкыр уздырыла торган яшь башкаручылар конкурсын үткәрү. 13-14 апрельдә сайлап алу турлары Казанда тәгәлләнеп, 15 майда Зур концерт залында гала-концерты булачак. Озак еллар дәвамында жюри рәисе булып торган Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Илһам Шакировны быел Ренат Ибраһимов алыштырачак. Фестивальнең тагын бер максаты – яхшы, сыйфатлы репертуар туплауны максат итеп куйган «Яңа татар җыры» конкурсын үткәрү.

Фотолар: matbugat.ru

Өченчесе – продюсерлык системасын үстерү, аны профессиональ дәрәҗәгә күтәрү.

– Бу мәсьәлә шактый катлаулы, чөнки татар сәнгатендә ул әле яңа күренеш. Ә яңалык һәрвакыт каршылыклар аша уза. Моңа кадәр безне социаль челтәрләрдә һәрвакыт «чеметеп» китәләр иде. Быел «Болгар радиосы» милли музыкаль премиясендә продюсерларга да игътибар иттеләр. Мин бу вакыйганы социаль борылыш булачак кабул иттем. Шуңа күрә киләчәктә продюсерлык үз урынын алыр дип уйлыйм, – диде Рифат әфәнде.

Фестиваль быелдан «Татар җырының алтын хитлары» дип аталган тагын бер серия концертлар башлап җибәргән. Проект авторы сүзләренчә, алар мәшһүр композитор Рим Хәсәнов белән хезмәттәшлек итә. Киләчәктә Зур театр солисты Венера Гимадиева белән дә эшләргә планлаштыралар. Аннан соң тагын бер зур эш – татар эстрадасының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге дигән фәнни хезмәт язу.

Татар музыкасын үстерү турында закон кабул ителерме?

Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев татар музыка сәнгатендәге проблемаларга аеруча зур басым ясады.

– Беребез дә битараф кала торган өлкә түгел бу. Әгәр татар халкының киләчәге турында уйлыйбыз икән, бөтен ягын да кайгыртырга тиешбез. Тел турында закон кабул иттек. Ә ни өчен әле безгә татар музыкасын үстерү турында закон кабул итмәскә? Шушы мәсьәләне дә күтәреп чыгарга кирәк. Безнең сәнгатьнең тагын бер зур проблемасы – балалар өчен язылган әсәрләрнең бик тә аз булуы. Бүген балалар концертларын куярлык репертуарыбыз юк. Нишләргә соң? Бәлки фонд каршында секция булдырып, кечкенәләрне җәлеп итәргә һәм балалар җырына конкурс оештырыргадыр? Аларның үзләренең җырлары булырга тиеш бит, – диде ул, ачынып.

Бервакыт Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов Татарстанда музыкаль драма театры оештыру турында күтәреп чыккан иде. Тик ни сәбәпледер, әлеге мәсьәләгә тиешле дәрәҗәдә игътибар итеп бетмәде. Бу мәсьәләне Разил Исмәгыйлевич кабат искә төшерде.

– Президент хуплаган икән, бу мәсьәләне кабат күтәреп, очына чыгарга кирәк. Әгәр аның үз бинасы булса, барысына да урын табылыр иде, – диде ул.

Ирек ШӘРИПОВ, Татарстан халыкларының Дуслык йорты директоры, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре:

– 10 млн га якын акча – халык акчасы. Фестиваль аны, үзенең хезмәте белән тулысынча, халыкка кире кайтарып бирә ала торган оешма. Аз да җитә, күп тә бетә, әмма бирелгән акчаны иң бәрәкәтле тотучы оешма – Ваһапов фестивале. Кассадан билет сатыла икән, димәк, фестивальнең халык арасында да даны, дәрәҗәсе бар.

Индус ТАҺИРОВ, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе

– Кайгыртучылар советын булдыру бик кирәкле эш. Без моңнан яралганбыз. Ул саклана икән, димәк, татар да саклана. Рифат, бөтен татар дөньясын барлап чыгып, иң сәләтле яшьләрне сайлап алды. Рәхмәт аңа. Бу эшкә ярдәм итү һәрберебезнең дә бурычы булырга тиеш. Эстраданы яхшырту, миллилеккә йөз бору – фестивальнең бурычы. Дәүләт тарафыннан да ярдәм булсын иде. Яхшы бинаны да дәгъваларга кирәк.

Разил ВӘЛИЕВ, Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе:

– Бүген бездә фондлар, фестивальләр күп, ләкин аларның берсе дә артык түгел. Кайсы уңышлырак эшлидер, кайсы бик үк яхшы түгелдер, әмма аларның һәммәсе дә кирәк. Бүген эстрадада 200-300 җырчы бар, диләр. Мин аларын да күпсенмим. Аларның яхшылары кала, ә бик үк камил булмаганнары акрын-акрын гына коелып төшеп бара. Һәр фестивальнең үзенчәлеге бар. Ваһапов фестиваленең үзенчәлеге ул – системалы рәвештә һәр көн эшләү. Киләчәктә, бәлки, һәр концерттан соң җыелышып, тәфсилле анализ ясаргадыр. Безнең Совет ике төрле юнәлештә барырга тиеш – рухи һәм матди ярдәм. Репертуар сайлаганда, шагыйрьләргә үз фикеребезне җитдирәк итеп җиткерергә кирәктер. Җырларның милли нигезе юк бит. Шуңа күрә төп принцип – җырларыбызның милли нигезен булдыру һәм югалтмау.

Янаркошны барыбыз да яраттык

Футбол буенча быел Конфедерация кубогы һәм 2018 елда Дөнья чемпионаты матчларын карарга киләчәк тамашачыларны «Казан-Арена» футбол стадионы капка төбендә дүрт метрлы чәчәк каршы алачак. Ышанмыйм димә, Казан бу!



Авторның фотоархивыннан

– Башкаланың Татарстан урамындагы Барс һәм Меңьеллык мәйданындагы Янаркош чәчәк сыннары казанлыларның да, кунакларның да күңеленә хуш килде. Төрле илләрдән килгән туристлар шул сыннар янында озаклап фоторәсемгә төшәләр. «Казан-Арена» стадионы территориясенә «FIFA» дип язылган дүрт метр биеклектәге яшел инсталляция урнаштырыла. Ул да бик матур булачак, – дип хәбәр итте «Горводзеленхоз» тресты идарәчесе Роза Җаббарова.

Универсиада проспектында «Футбол тубы», Казан Кремлендә чәчәкле аркалар, «Күбәләк» чәчәк сыннары тирә-юньгә ямь тарата.

Казанның Меңьеллык мәйданындагы Янаркош сынын күреп сокланмаган кеше бармы икән? Янаркошның койрыгы гына да ярты гектар мәйданны билгән төрледән-төрле меңләгән чәчәктән гыйбарәт.

– Казанда 366 гектар мәйданны биләп торган 137 паркка, бакчага, скверга һәм 4 мең гектарда Аккош күле шәһәр урманына хезмәт күрсәтәбез. Парклардагы кече архитектура сыннарына буяу белән язмасыннар иде, – дип үтенә Роза Җаббарова.

Трест питомнигында 20 исемдәге 1,4 миллион төп берьеллык чәчәк үсентесе үстерелә. Алар Казанда 21 мең квадрат метр мәйданда утыртылачак.

– «Горводзеленхоз» тресының шәһәрне яшелләндерүдәге хезмәте мактауга лаек, – диде мэр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин шәһәр башкарма комитетындагы киңәшмәдә. – Казандагы паркларны хәстәрләүгә республика тарафыннан ярдәм арттырылды. Чәчәкләргә карата «күп булды» дип әйтеп булмый, мөмкин кадәр күбрәк мәйданнарда утыртылсыннар. Казан ямьле булсын!

Дамир БӘДРИЕВ.

«Алтын битлек» кемгә булыр?

Быел Мәскәүдә узачак «Алтын битлек» Россия халыкара театр фестиваленә Татарстаннан ике спектакль тәкъдим ителә.

12 апрель көнне Мәскәү курчак театры сәхнәсендә Илгиз Зәйниевнең «Сак-Сок» (Чаллы курчак театры) спектакле күрсәтелә. Ул «Курчак театрында иң яхшы спектакль», «Иң яхшы режиссер эше», «Иң яхшы рәссам эше» дигән номинацияләрдә тәкъдим ителгән. Исегезгә төшерәбез, «Һөнәр» фестивале вакытында әлеге спектакль Казан тамашачысына да күрсәтелгән иде. Бу көннәрдә ул кабат Казан сәхнәсендә куелыр дип көтелә.

Казан яшь тамашачы театры куйган «Из глубины... (Художник Винсент Ван Гог)» дигән спектакль 14 апрель көнне сәхнә тотачак. ТЮЗның, беренчеләрдән булып, «Алтын битлек» премиясенә ия булган театр икәнен дә онытмаска кирәк. Моннан егерме ел элек Борис Цейтлин куелышындагы «Буря» спектакле «Алтын битлек» премиясенә ия булган иде.

Җиңүчеләр 19 апрельдә билгеле булачак.

«Татармультфильм» студиясе – җиңүче

«Татармультфильм» студиясе әзерләгән «Туган авылым» музыкаль клибы XXII ачык Россия анимацион фильмы фестивале версиясе буенча 2014-2016 елларның иң яхшы музыкаль фильмы дип табылган, дип хәбәр итә Казан мэриясе порталы.

Өч минутлык анимацион роликта татар халкының «Шүрәле» әкиятенең баш герое туган як урманы, туган ягына булган мәхәббәте турында җыр башкара. Татарстан студиясе клибы музыка белән тыгыз бәйләнгән 100дән артык анимацион эшне узып киткән. Җиңүче исеме өчен Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре, Европа һәм Америкадан һәвәкәскәрләр һәм профессионаллар көрәшкән.

«Дулкыннар»да нәфис сүзне яратучылар күп

Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән «Идел» яшьләр үзәге тарафыннан оештырылган XII «Дулкыннар» республика бәйгесе быел халык шагыйре Разил Вәлиев иҗатына багышлана. Бәйге вокал, нәфис сүз, рәсем номинацияләрендә төрле яшьтәге балалар арасында уза.

Быел бәйгедә балалар бакчаларына йөрүчеләр дә катнашачак. Конкурска 1134 гариза кабул ителгән. Нәфис сүз төрендә катнашырга теләүчеләр саны 500гә җитә. Катнашучыларга вокал һәм нәфис сүз буенча бәяне танылган артистлар, рәсем төрендә күренекле рәссамнар бирәчәк. Жюрида Разил Вәлиев үзе дә булачак.

–Элек безнең конкурста катнашкан яшьләр арасында бүгенге көндә танылган башкаручылар, артистлар да бар. Мәсәлән, Зәринә Хәсәншина, Артем Пискунов, Сәйдә Мөхәммәтҗанова шундыйлардан. Без алар белән һәрвакыт кызыксынып торабыз, – ди «Идел» яшьләр үзәге җитәкчесе Ләйсән Сафина.

Жюри әгъзасы Сәгыйть Муллануров әйтүенчә, бәйгенең балаларда зәвык тәрбияләүдә әһәмияте зур. Балаларның башкару осталыгы елдан-ел арта бара. Аларның үзләре язган шигырьләрен укулары да сөендерә. Әгәр «Дулкыннар» булмаса, кайсы композиторның иҗатын җентекләп өйрәнә алырлар иде икән?

– «Дулкыннар» бәйгесе минем балачактагы хыялымны тормышка ашырырга мөмкинлек бирде. Мине шунда күреп, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенә эшкә чакырдылар, – ди Айзилә Батрханова.

Конкурста бернинчә тапкыр катнашырга да мөмкин. Чикләү бары тик бәйгедә Гран-прига ия булучыларга гына кагыла.

Конкурсның йомгаклау концерты 17 мартта Халыклар дуслыгы йортында узачак.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ВАЗИФАСЫН БАШКАРУЧЫ
Илсөяр Илфруз кызы Вәлиуллина.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 687. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы